Гүзәл Гайфиева

Рифат Сверигин

Ерактагы кыяларга карап…

“…бер хыялый теләк туды әле. Әгәр, димен, дөнья әдәбиятыннан иң яхшы хикәяләр бергә туплап чыгарылса?! Һәм бу басма татарча булса!...Укучыбызга бүләкнең дә бүләге булыр иде ул!”

( Мәгъсум Хуҗин көндәлегеннән )

Хикәяләр остасы Мәгъсум Хуҗинның бу теләге тормышка ашса, әлеге җыентыкта язучының үз әсәрләре дә урын алыр иде. Гомерләре дәвамында, аның кебек гел хикәя, новелла, кечкенә повесть жанрларына табынып иҗат иткән башка каләм әһелләрен татар әдәбиятында бүтән очрамый дисәң дә ярый.

Каләм тибрәтүчеләрнең кайберләре кечкенә жанр формаларын башка эрерәк жанрларга сикереп менү өчен баскыч такта, ягъни трамплин рәвешендә файдаланырга тырыша. Андыйлар, күрәсең, “нәрсә соң ул хикәя?...менә роман белән күренсәң – анысы бөтенләй башка!...шунда ук сине танып алачаклар – роман язып карамаган кеше прозаик була димени…” дип уйлый торганнардыр… Болай фикер йөртүчеләр бер әйберне оныталар: җыйнак жанрларның да үз югарылыклары, үз биеклекләре була... һәм анда күтәрелү, ай-һай, һәркемнең көченнән киләме икән? Чөнки ул гаҗәеп нечкә зәвык, әдәби техниканың үтә дә камиллеген һәм сәнгатьне, тормышны үзенчәрәк күрә белүне сорый.

Әйе, әдәбиятның мондый кыяларына О Генри, Ги де Мопассан, Голсуорси, А.П.Чехов, Әмирхан Еники. Фатих Хөсни, Айдар Хәлим кебек әдәбиятның чын альпинистлары,титаннар гына күтәрелә ала.

Мәгъсум Хуҗинның бөтен иҗаты тулысынча диярлек гел хикәяләрдән генә тора. Ул күләмле сюжетлар иҗат итәргә омтылмады да. Әдәбият галиме Фәрит Хатипов аның турында: “Мәгъсум Хуҗин – бөтен иҗат юлында шушы җыйнак һәм шул ук вакытта ифрат катлаулы, үзсүзле жанрга тугрылык саклаган, бу өлкәдә бай тәҗрибә туплаган, күзгә күренерлек нәтиҗәләргә ирешкән сирәк әдипләрнең берседер”, - ди. Язучы әлеге жанрны илаһи югарылыкка күтәрергә тели. Ул “әдәбиятта хикәя иң өстене” дип, аны сүз сәнгатенең башка төрләреннән аерып куя, беренчел дип саный. – “...хикәя язып көн күрергә тырышам мин, - ди ул. - Һәм, шөкер, көнне күрәм, чөнки һәр ак таңда – төнне көн алыштырганда шөкер, тәпи баскан булам” ( “Мәдәни җомга”, 1995 ел, 28 июль).

Яңа көн тууы, тормышның һәр мизгеле, һәр бизәге - әдип өчен иҗат этәргече, илһам чишмәсе. Шуңа күрә әсәрләре дә тормыш матурлыгы, кояш яктысы, шигъри мәгънәлелек белән сугарылган. Мәгъсум Хуҗин гомере буена күңеле белән авылдан, туган-үскән яклар табигатеннән аерыла алмады һәм аерылырга теләмәде дә, һәм, игътибар итегез: ул үзе күргән-белгән авылның элеккеге хәлләрен дә һәм хәзерге яшәешен дә бердәй дөреслек белән реаль рәвешендә, үз төсләрендә бирә алды. Мәгълүм ки, татар прозасында авыл турында язучылар аз булмады. Әмма әлегә без аның үткәне белән хәзергесен бер үк дәрәҗәдә, бердәй осталык белән үз төсләрендә тасвирлый һәм бергә бәйли алган бер генә башка татар әдибен дә күрсәтә алмыйбыз. Хәтта Мәхмүт Галәү, Мәҗит Гафури, Гомәр Бәширов, Фатих Хөсни, Рафаил Төхфәтуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев кебек бөекләребез дә билгеле бер дәвер авыл халкы турында гына язарга җөрьәт иттеләр.

Шушы мәгънәдә М.Хуҗинның авыл прозасы диапазонының вакыт ягыннан киңлегенең, әлбәттә, үз сәбәпләре бар. Аны, мөгаен, авторның иҗат позицияләре белән тыгыз бәйләнештә карап кына аңлатып була торгандыр. Бу урында М.Хуҗин иҗатының кайбер өлешләрендә матур әдәбият белән публицистиканың кушылгалап китүе хакында искәртү дә кирәктер, ахры.

Шулай да вакыт киңлеге автор тематикасының чиксезлеге дигәнне аңлатмый. Киресенчә, җирлек яисә география ягыннан караганда, бу прозаның контур-ызаннары бигүк еракта түгеллеге дә бик ачык күренеп тора. Язучы темалар, образ-сурәтләр, герой-персонажлар сайланышына да үтә игътибарлы, талымлы һәм бик таләпчән. Алга таба без шул чикләргә дә күз салырбыз, әдипнең кабатланмас үз йөзен, стилен, үзенчәлекләрен билгеләргә тырышырбыз. Ә бу үз чиратында мәкаләбезнең төп максатына якынлашырга да булышыр.

Мәгъсум Хуҗин Саба ягы – һөнәрчеләр – зәркәнчеләр (көмешчеләр) төбәгеннән. Бу һөнәр ияләренә хас булган холкындагы төгәллек, нәзакәтлелек әдипнең әсәрләрендә дә чагылыш таба. Ул хикәянең төзелеше, эчтәлеге, формасының килешле бөтенлегенә нык игътибар итә. Оста зәркәнчеләр төсләрне, бизәкләрне ничек сайлап урнаштырса, әдип тә сүзләр белән аларча эш итә. “Хикәя аңа бернәрсә дә өстәрлек, һәм аннан бернәрсә дә алып ташламаслык итеп язылырга тиеш”, дигән танылган хикәяче Сомерсет Моэм. М.Хуҗин да шул принципка таяна. Алга таба без моны әле күп хикәяләре мисалында да күрербез.

М.Хуҗин әсәрләрендә күбрәк Татарстанның Саба һәм Теләче ягы авыллары сурәтләнә. Ул үзе дә Саба төбәге кешесе, яшьлеге дә шунда үткән. Саба урта мәктәбен тәмамлагач, шунда беркадәр укытучы булып, аннан районның яшьләр оешмасында һәм газетасында эшләгән. Узган гасырның илленче елларында әлеге ике район бергә булып, аларда икесенә йөзгә якын авыл саналган. М.Хуҗин шул авылларның барысына да кереп, йөреп чыга, кешеләре белән таныша, сөйләшә, яңа тәэсирләр ала - һәм, фәкать шунан соң гына, ул шушы төбәк турында язучылык сүзен әйтергә, иҗади фикер йөртергә үзен хаклы дип саный.

Крестьян хезмәтенең дә бар хасиятләрен, нечкәлекләрен, шатлыкларын һәм кыенлыкларын яхшы белә һәм үз итә ул. Менә шуңа бер генә мисал:

“Лобогрейка әвернәсенең арыш өстеннән тәгәрәп килүен күрәсең, келтерәвек тавыш йөгерек көй булып ишетелә. Тезгеннәрен камыт бавына гына бәйләгән атлар. ялкауланып-иренеп, көлтә йөге тарталар. Уракчы апалар учманы, һавада каерып-селтәп, көлтәгә салалар. Аннары сугу машинасының түбәсенә менеп баскан ике апаның өлгерлегенә сокланасың. Алар барабанга көлтәне таратмыйчарак бирсәләр, машина ачуына чыдаша алмыйча, үкереп куя. Сугу машинасының арткы башында тузан-кылчыкка күмелгән кызлар, кара-каршы парлашып, изелеп-вакланып чыккан саламны ары этәрәләр һәм малайлар, атларын чаптырып килеп, өемне бастырып эләктереп, эскерткә алып китәләр. Сугу машинасының түбәнге ике улагыннан, сортларга аерылып, агач әрҗәләргә арыш ага...” (Хуҗин М.Ерактагы кыялар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 1990. – 185 б.).

Искиткеч төгәллек белән сурәтләп, иңләп алынган бу күренеш инде үтеп киткән гасырның кырыгынчы-илленче еллар авылында характерлы технологик процессны күрсәтү өчен генә язылмаган. Мондый юлларда шушы хезмәт эчендә кайнап, чыныгып үскән, эшнең кадер-кыйммәтен гомер юлы дәвамында канына-җанына сеңдерәчәк яшүсмернең һәм авторның үзенең дә барыбызны да ашаткан-яшәткән авыл кешеләренә чиксез ихтирам-хөрмәте дә чагылып үтә: “Монысы җир агаеның күзгә күренеп торган җимеше инде. Мин әнә шул көшелләргә китереп бушатырга ярата идем, көшелләрнең һаман зураюына шатлана идем”.

Мондый өзекләрдә игелекле крестьян һәм язучылык хезмәтләренең бердәй профессиональ югарылыкта үзара кушылуларын да күрергә була. Хәзерге авыл күренешләре-хәлләре турында язганда да автор шул биеклектән төшми. Чөнки аның образлы фикерләвендә авылның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге яшәешнең тоташ бер чыганагы, тормышның җитди һәм олы мәгънәсе рәвешендә бер бөтен булып берләшә.

Мәгъсум Хуҗин әдәбиятка 1950-1960 нчы елларда килә. 1961 нче елда басылып чыккан “Ерганак юл яра” дигән тәүге китабыннан соң дистәдән артык хикәяләр җыентыклары дөнья күрде. “Курагай атлары” (1973),

“Авылым урамнары” (1978), “Урманлы үр” (1980), “Өч каен ышыгы” (1984), “Бәхет җире” (1987), “Урак өсте болытлары” (1988), “Ерактагы кыялар” (1990), “Айның уты сүнгән” (2004) җыентыкларына урнаштырылган күп санлы хикәяләрендә ул үз карашларына, уй-принципларына гел тугрылыклы булып калды. Әдип әсәрләрендә кеше күңеленең төрле якларын ачарга омтыла, чор фаҗигаләрен аерым кеше язмышлары аша тасвирлый. Нинди генә кыенлыклар кичерсәләр дә, М.Хуҗин геройлары югары әхлак, кешелек сыйфатларын югалтмыйлар. Җаннары заман кырыслыгыннан, җәберләрдән һәм имансызлыктан, тупас мөгамәләләрдән биртелерлек, имгәнерлек шартларда да алар кеше булып калалар. Фани дөньяның гади генә матурлыгыннан да илаһи ямь табып яшәүче Шимай (“Мәк чәчәге” хикәясе) һәм Биюш (“Ак колын”), туган туфрагына һәм үз кыйбласына тугры Юлмәти (“Юлмәти бәйрәме”), бүтәннәр шатлыгын үз күңеленнән кичерүче Зөлфия (“Җитәкләшкән таллар”) әнә шундый геройларның кайберләре генә. Алар – авылның гади кешеләре, җаннары-тәннәре белән җиргә береккән кешеләр. Туган җир, туган туфрак – алар өчен иң газиз, иң изге нәрсәләрдән.

М.Хуҗин прозасына һәм андагы геройларга аеруча бер сыйфат – тыйнаклык хас. Алар үзләренең бай рухи кичерешләрен, асыл халәтләрен-хәлләрен шактый тирәнгә яшереп яшиләр, очраган берәү алдында түгел, хәтта укучының үз каршысында да бөтенләй түгелеп-ачылып бетәргә торучылар рәтенә кермиләр. Алар – горурлар, үз дәрәҗәләрен, үз кадерләрен белеп, үзләренчәрәк яшәүче кешеләр. Горур һәм үзисәпле дигәч тә, башка сыйфатларын телгә алганда да, яисә башка очракларда да чик-чама дигән әйбернең бик нык саклануы, шул чикләрне һич тә узып китмәү дигәнне искәртергә кирәк була.

Югыйсә, билгеле бер уңай характер сыйфатларын нык үстереп, көчәйтеп, рельефлы ныгытып сурәтли белгән әдипләребез дә байтак бит. Әмма М.Хуҗин геройларын А.Гыйләҗевның җаннары газапланып, гасабиләнеп яшәгән Мирвәли, Шәмсегаян (“Өч аршин җир”), Исхак (“Берәү”), Бибинур (“Җомга көн көч белән”), яисә Р.Төхфәтуллинның үтә

нечкә лирик җанлы Гөлзифасы (“Йолдызым”), тынгысыз, узынучан характерлы Нәбие (“Авылдашым Нәби”) яисә Гомәр Бәшировның гел бер омтылыш-максат: ил-көн алдында йөз аклыгын саклап, намуслы булып яши белгән Нәфисә (“Намус”) кебекләр белән янәшә куеп чагыштыру дөрес булмас иде. Атаклы драматург Туфан Миңнуллин әсәрләрендә еш очрый торган, үз-үзләренә нык ышанган, үзенекен ничек кенә булса да тормышка ашырырга гадәтләнгән, үҗәтрәк характерлы персонажлар белән дә аларның уртаклыгы юк.

Бу урында менә мондый бераз сәеррәк, аңлатуы кыенрак һәм бәхәсләргә урын калдырырлык уй да башка килә: әллә кешеләрнең характер сыйфатларының күркәмнәре дә, бигүк килешеп-ярашып бетми торган яклары да аларның яшәгән тирәклекләреннән, төбәкләреннән киләме икән?.. Фикеребезне раслау өчен М.Хуҗинның “Урак өсте болытлары” повестеннан бер өзек китерәбез: “Кылыкта (Кылык – Саба ягы авылларының берсенең уйлап чыгарылган атамасы, эзләнсәң, аның прототибын да табып булыр иде – (Гүзәл Гайфиева, Рифат Сверигин), иске китаплардагыча әйтсәк, ләүхелмәхфрүзнең (язмышның, тәкъдирнең) тискәре ягында чуалгалап беткән, кайгының күзенә туры карауччы, бәлки шуңа күрәдер, кырысрак, хәтта кырыс-кире холыклы, әмма төп сыфатын алга чыгарсаң, эш рәтен белүче кешеләр яши” (Хуҗин М.Х. Урак өсте болытлары. К.: Татар.кит.нәшр. – 1988. – 31 б.).

Эш рәтен белүче кешеләрне, әлбәттә, һәркайда табып була. Әмма М.Хуҗин андыйларны күбрәк үз ягында – Кылык һ.б. исемнәр белән аталган авылларда – Саба, Балтач, Теләче төбәгендә табарга тырышкан һәм тапкан да. Бу якларның, Мишә, Шушма буйларындагы урман-тугайларның бигүк күзгә ташланмаса да, кадерен-кыйммәтен белүчегә тиз йогучан сихри кырысрак матурлыгын Мәгъсум Хуҗин кебек проза теленә күчереп җырлаучы әлегә кадәр юк иде дисәк, бераз гына арттырып җибәрү булыр шикелле. Чөнки әлеге гүзәл төбәк байтак вакытлар Фатих Хөсни прозасын да сугарып торды. Әмма хөрмәтле әдибебез, халык язучысы Ф.Хөсни шул

матурлык уртасында яшәүче кешеләрне үзенең нечкә күңелле, лирика тулы йөрәге аша кичереп, аларга сокланып, һәр кешенең аллы-гөлле бизәкләрен җанлы халык теленең искиткеч җәүһәрләренә үреп тасвирлаган булса, М.Хуҗин башка төрлерәк юл сайлый. Ул үзе дә характеры, карашларының тормышчан реальлеге белән авыл сферасының яшәешенә, аның бүгенге халәтенә, икътисади шартларына һәм бигрәк тә тәҗрибәле, төпле, аек фикерле авыл кешесенә - хәзерге татар крестьяннарына, әлбәттә, якынрак тора.

Бу урында М.Хуҗинның әдәбияттагы биеклекләре, позицияләре ныклы җирлеккә нигезләнгәнлеге хакында да әйтеп үтү артык булмас кебек – ул әдәбият дөньясына һич тә очраклы гына килеп кергәннәрдән түгел. Моннан күп еллар элек – илленче-алтмышынчы елларда ук башланган иҗат тәҗрибәләре, 1960-1970 нче елларда зур ташкынга әверелеп китте, ә шул сиксәненче-туксанынчы елларда, яңа гасыр чикләрендә өр яңа сыйфат үзгәрешләре белән баеды.

Аның әсәрләренең геройларының күбесе үз хезмәтләре, үз тырышлыклары, үз осталыклары һәм үз акыллары белән яшәргә күнеккәннәр. “Кеше, иң беренче нәүбәттә үз-үзенә таянырга, үз юлын үзе таба белергә тиешле” дигән бу тезисның асыл мәгънәсе шактый ук тирәндә ята. Аның нигезенә дөньяның алдынгы әдәбиятларын меңъеллар буена сугарып килә торган гуманистик идея – кешенең рухи, гражданлык, социаль эстетик һәм физик азатлыгын яклау салынган. Мәсьәлә, күренешләрнең икътисади һәм эстетик якларына аеруча нык басым ясала. Ә инде һәртөрле өстән кушулар, көннең модадагы конъюктурасы, оста һәм матур сөйләгән булып, демагогия аша тормышка ашмастай хыялларга ышандырырга чакыру-өндәүләр барысы да крестьян хезмәтенең олылыгы һәм заруриылыгы янында кирәкмәгән буш куыкка әйләнеп кала.

Әдип татар әдәбиятында байтактан үткәреп киленгән “барысының да нигезендә хезмәт һәм аны ярату ята” дигән кире какмаслык нигездә дөрес тезистан да арырак китә. Ярату гына җитми, тик эшнең рәтен белеп

эшләгәндә генә хезмәт икътисади нәтиҗә һәм эстетик канәгатьләнү бирә, ә моңа ирешү бигүк җиңел эш түгел. Ул әле, яшәүгә сусау, аңа омтылыш, тормыш дәвам итсен өчен көрәшә белү, яшәү һәм тормыш көченең тантанасына ирешү өчен үзеңне бар булганыңча багышлау кебек Джек Лондон, Эрнест Хемингуэй идеяләренә килеп тоташа.

Болай яшәргә өйрәнү бик яшьтән башлана.

“Таң тавы белән Мишә тугае арасында сазлык бар. Шүрәле сазлыгы диләр аны. Йөгереп чыныгыр өчен такыр сукмаклар гына аз авыл балаларына, тормышның яшерен көчкә ия баткакларын читләтеп үтәргә өйрәнү өчен түмгәкле сазлык та кирәк аларга. Авыл кешеләренең түмгәктән-түмгәккә сикереп шикләнүләре яши Миһербанлы сазлыкта!” ((Хуҗин М.Х. Урак өсте болытлары. К.: Татар.кит.нәшр. – 1988. – 31 б.).

Әнә шундый тормыш сазлыкларын, сынау-сыналу кырларын, полигоннарын узганда батмаган, имгәнмәгән, исән-имин калган кешеләр алар М.Хуҗинның яраткан геройлары. “Урак өсте болытлары” повестенда да аларның кайбер матур үрнәкләре бар. Мәсәлән, колхоз төзелгәннән бирле, аның башында торып, үзе шикелле үк крестьяннар бәхетен кайгыртып йөргән Газизҗан карт та, атасының юлын инде башка шартларда да уңышлы дәвам иттерүче Әмирҗан да, үз тәҗрибәләре янына, әйләнә-тирәдәге башкаларның акыллы фикерләрен кушып эш итүчеләр буларак зур хөрмәт уяталар.

Андыйлар белән танышканда, Мәгъсум Хуҗинның гражданлык һәм эстетик карашлары күп тапкырлар җил-давылларда сыналып, яшәү хокукын раслаган ныклы өрлек баганаларында утыруына янә бер кат ышанасың. Моның сәбәпләрен еракта эзләп торасы да юк. Беренчедән, автор дистәләгән еллар буена журналистлык хезмәте башкарганда күп җирләр-сулар кичеп, кемнең кем икәнлеген тиз һәм дөрес таныргa өйрәнгән. Икенчедән, ул үзе дә ихтирамлы-таләпчән шартларда тәрбияләнгән һәм бу сыйфат аның үз характерына да күчкән – моның өчен ул, әлбәттә, гомеренең зур өлешен күмәк хуҗалыкны җитәкләүгә багышлаган әтисенә - Хәмит ага Хуҗинга бурычлы.

“Урак өсте болытлары”ндагы Газизҗан картның прототибы, чыннан да, Хәмит Хуҗин. Әйе, без хәзер күп уйлап тормыйча гына каргарга, сүгәргә күнеккән тормыш этапларында – илне колхозлаштыру, индустрияләштерү чорында да әйләнә-тирәдә, яхшы кешеләр, чын җитәкчеләр дә яши иде.

Бик күпләр ул елларда ГУЛАГ лагерьларында харап ителсәләр дә, җәлладлар бар халыкны да кырып бетерә алмадылар. Илдәге шартлар, тәртипләр кайберәүләрне тормышка җайлашуга, икейөзлелеккә дә этәрде. М.Хуҗин шул чорда да ихлас күңелле, намуслы, чын кеше булып калганнар турында, аларның каршылыкларны җиңәбез дип төрле кыен хәлләргә дучар булулары аркасында җибәргән ялгышлары турында да яза.

“Юл өзеге”, “Урак өсте болытлары”, “Кулаклар колхозы” әсәрләрендә мәгълүм елларда авылны күмәкләштерү хәрәкәте үзенең күп төрле кыенлык-каршылыклары, дәһшәтле кырыслыгы белән гәүдәләнә. Шулай да Мәгъсум Хуҗин бу юлдан атларга җөрьәт иткән бердәнбер татар әдибе түгел. Беренче омтылышны шул елларның үз кайнарлыгында, үз рәвеше һәм үз буяуларында сурәтләргә тырышып яшь язучы Фатих Хөсни ясаган иде (“Утызынчы ел”, 1931). Әмма ул вакытта болай язарга ярамаганлыгын аңа бик усал аңлаттылар. Тик тагын утыз еллар үтеп, илдә сәяси атмосфера бераз гына йомшара төшкәч, анда да бик сакланып кына шул олыгая төшкән әдип шул романын яңабаштан үзгәртеп, төзәтеп эшләп чыкты (“Утызынчы ел”, 1961). Әлеге “бөек хәрәкәтнең” кеше язмышларының астын өскә әйләндерүче, сыйнфый көрәш бәрешләренең кеше бәгырьләрен телгәләп, күңелен, психикасын актарып үтүен Аяз Гыйләҗев (“Өч аршин җир”, 1961) һәм Мәхмүт Хәсәнов (“Язгы аҗаган”, 1985) кыю күтәрделәр.

Мәгъсум Хуҗин исә колхоз-совхоз шартларында илле-алтмыш ел дәвамында яшәгән татар авылын, аның хәлен, яшәешен максималь төгәллегендә, күз иңли алганча, киңлегендә һәм объективлыгында ачып бирергә омтыла. Аңа “вакыт, дистанция күзлеге” дә ярдәм итә - ул үткәннәр инде тарихка әверелгәч, шул тарихны белгән, кичергән бүгенге кеше күзлегеннән карый. Һәм менә нәрсәләр аңлашыла: әнә шул сынауларны

кичергән крестьян буыннары чорның иҗтимагый кагыйдәләренә ышанып, алга таба тормышлар рәтләнер дип өметләнеп яшәде, үзе гел үк канәгать булмаса да, һәртөрле мәшәкать-кыенлыкларны үз тормышының вакытлыча котылгысыз, аерылгысыз бер өлешедер дип аңлады - әлбәттә ул, башка бик күпләребез кебек социализм һәм коммунизмның өрфиядәй пәрдәләренең алдавыч рәшә генә икәнлегенә төшенә алмады – хәер, бу халәт коммунизм сихеренә исертелгән бөтен илнең фаҗигасе иде.

М.Хуҗин каләме әнә шул тормышка ашмаган хыялларны, күңелдә яңартып, кат-кат бәгырьләргә кадап, гел чәнчеп торганнардан түгел. Ул гомерләре инде тәмамланган яисә тәмамланып килә торган буыннар тормышларының да үз яме, үз матурлыгы, ниндидер шатлык-бәхетләре, кайгы-борчулары, ягъни гади кешеләрнең (бу гадиләр рәтенә колхозчылар да, механизаторлар да, рәисләр дә, һәртөрле идарә башлыклары да керә) гомер юллары турында сөйли. Хакимиятче фирка, юлбашчылар аларга сәяси-социаль генераль юлларны, төп платформаны алдан әзерләп куйган булсалар да, бу гадиләр шул “даһилар” сызганнарны да үзләренчә үзгәртеп, үз җайларына, ягъни кешечәрәк рәвешкә борырга тырышканнар, шул шартларда шәхси биографияләрен төзи алганнар. Менә шундый җирлектә М.Хуҗин искиткеч кызыклы, гыйбрәтле тормыш мәйданын таба, шул аренага укучыларын да алып керә. Ул кире кагылмаслык документаль фактларга да таяна – аларның бик күбесе 1927-1931 елларга, ягъни “бөек борылыш” яисә илнең “бөек сынау” үтүе, үзгәрүе дип йөртелгән чорга карый.

“Юл өзеге”, “Урак өсте болытлары”, “Кулаклар колхозы” әсәрләренең һәр кайсында авыл хуҗалыгын күмәкләштерү кампаниясе чорындагы авылның көн сулышын, яшәешен чагылдырган конкрет күренешләр бар. Мәсьәләнең асылын аңларга тырышу, бу хәлләрнең очлары-сәбәпләре кайларга барып тоташкан да, аның көчле һәм кырыс кайтавазлары хәзерге заман кешеләренең язмышларына нинди йогынты ясый - әсәрләрдә әнә шулар белән бәйләнгән уйлар өстенлек итә. Автор үз укучысы алдына гадәти кабинет, бүлмә язучысы буларак түгел, ә туган төбәгенең – Саба якларының

тарихы белән якыннан кызыксынучы тынгысыз журналист, публицист булып, шул җирдә яшәүчеләрнең язмышларын күңеле, йөрәге аша үткәрүче газиз якташы булып күз алдына килеп баса.

"Урак өсте болытлары" (1988) исемле әсәр татар авыл прозасына зур әдәби яңалыклар, табышлар алып килде. Аның төзелеше дә бик үзенчәлекле. Ул уртак исем белән үзара берләштерелгән 11 хикәядән тора. Аларның һәркайсын тәмамланган сюжетлы, мөстәкыйль әсәр дип санарга да мөмкин булыр иде. Әмма билгеле бер вакыт эзлеклегендә тезелгән шушы вакыйгалар бер бөтен булып үзара берләшкәч кенә аның тирән мәгънәви һәм хисси җегәрен яхшырак тоясың. Вакыйгаларның ике чор яссылыгында алып барылуы әсәрнең мәгънә сыешлыгын тагын да арттыра төшә.

Әсәрнең буеннан-буена крестьян күмәк хуҗалыкларын җитәкләгән, йөкнең иң авыр башын үз җилкәләренә куеп күтәргән колхоз рәисләре образлары тора. Хәзер шул үтелгән җитмеш совет елын аяк астына салып, таптап тиргәү аеруча модага кереп китте. Әмма бит шул елларда да төп йөкне җигелеп тартучы каһарманнар күп булган. Әсәр андыйларны да онытмаска чакыра.

"Юл өзеге" (1990) повестенең үзәгенә заманында республиканы шаулаткан суд процессына алып килгән вакыйга – Сабадагы авыл хәбәрчесе Закир Йосыповның вәхшиләрчә үтерелүе куелган. Шул мәгънәдә әсәрне криминаль-детектив повесть дип атарга да мөмкин. Чыннан да, әлеге җинаятьнең тамырлары- сәбәпләре, ничек башкарылуы җентекләп бирелгән. Әмма М.Хуҗин еш кына үз әсәренең бер генә яклы функциясе белән чикләнми. Монда да әсәр сюжетына берничә мәгънә йөкләмәләре салынган. Биредә күмәкләштерү чорының фаҗигасе драматизмын ачканда, тарихи документаль фактларга таяну да, әдипләрчә фараз кылулар да, төбәк тарихы белән бәйләнешле риваять-легендалар да мавыктыргыч янәшәлектә күрсәтелә.

Кыскасы, М.Хуҗин җыйнак кына әсәрдә маҗаралы повесть яратучыларга да, тарихчылар, этнографларга да, туган як тарихы белән

кызыксынучыларга да байтак рухи азык бирә. Әсәрнең күп функциональлеге дигәндә без шуларны да истә тотабыз. Автор үзенең әдәби-публицистик һәм тарихи тикшеренүләрендә уй-фикерләрен укучысы белән уртаклашканда ачык, самими һәм эчкерсез булып кала, башкалардан артыграк белүче һәм үзен генә хаклы дип санаучы, өйрәтеп кенә торучы “акыллыбаш” позасына басмый.

Халкыбызның тормышы-яшәеше күп гасырлар буена иген игеп көн итүче крестьян акылына-аңына, аның тәҗрибәлегенә, аек фикер йөртү сәләтенә, гаделлегенә, сабыр һәм мәгънәле эш йөртү гадәтенә нигезләнгән. Бәхеткә каршы, төптән уйлап, алдан күреп, исәпләп, тормыш йөген тарту сыйфаты күпләрнең каннарына сеңеп калган, бүген дә югалмаган. Чыннан да, җөмһүриятебезнең дөрес юлдан атлавы, татар ил агасының кылган акыллы эш-гамәлләренең тамырлары да әнә шулай еракларга барып тоташа сыман.

Халыкны әнә шундый күркәм сыйфатларыннан мәхрүм итү милләтебезнең киләчәгенә, булачак үрентеләренә балта чабу булыр иде. Ә бит тарихта нәкъ шуны эшләргә теләүчеләр һәм эшләп караучылар да байтак булган.

“Кулаклар колхозы” (1988) исемле хикәядә бер төркем аңлы һәм кыю крестьяннар авылны мәҗбүри күмәкләштерү кампаниясенә каршы чыгалар, үзләренчә яшәргә телиләр. Юртай авылындагы 12 хәлле хуҗалык колхозга керергә риза булмый. Бәйрәмхан, Шәйхетдин кебек крестьяннар үзәктән җибәрелгән вәкил белән бәрелешәләр: “Минем кендегем җиргә береккән. Ә сез колхозга тыгып, җирсез калдырырга ниятлисез, - ди Бәйрәмхан... – Мине кыеш әгитегезгә бүтән дәшмәгез. Мине кулак ясап кую белән дә өркетмәгез. Революция биргән җирнең файдасын табып яшәвемне беләсез. Акны кара дип атый алмассыз. Вөҗданыгыз булса...”

Әмма югарыдан җиткерелгән әмерне ничек тә үтәргә тиешле Бикмураевлар өчен бу дәлилле фикерләүнең бер кирәге дә юк. Кешеләрчә уйлашып, фикер алышып, бәхәсләшеп, мәсьәләне дөрес хәл итәргә тырышу алар өчен ят нәрсә. Көч куллану, тыю, куркыту – андыйларның төп коралы.

Ялгыз хуҗалык малларының көтүлекләрен бетерү, конфискацияләү, ә үзләрен кулакка санап, авылдан сөрү, юк итү... һәм боларның бөтенесенә югарыдан, үзәктән фәтва алып, шул гамәлләрне кансызлык белән башкару, ахырынача җиткерү...

Әле һаман да гаделлек барлыгына ышанып йөрүче крестьяннар үз күмәк хуҗалыкларын төзергә уйлыйлар, шуңа имза җыялар... Әмма югарыдан төшерелгән схемага бу һич тә туры килми – ишек барында тәрәзәдән йөрү кебек тоела. Нәтиҗәдә куркытып, көчләп, мәҗбүр итеп, ябып куеп, әлеге аерым колхоз инициаторларының ихтыярларын сындыралар... Гадел мөнәсәбәтләргә өметләнү, ышанычлар бөтенләй юкка чыккандай була. Олылар моны аңлый, бик күпләр баш иярга мәҗбүр булалар. Тик барыбер яшь үсентеләр кала. Шул чагында 9 яшьтә булган нәни Корбәт образы аша нәкъ әнә шуңа ишарә ителә. Бу нәнигә инде олыларның дөрес тәрбиясе сеңәргә өлгергән, ачы язмышлар аларны кая ташласа да, Корбәт кебекләр хөр фикерле, гаделлекне, азатлыкны яклаучылар булып үсәчәкләр...

Тик югалтулар гына артык күп түгелме соң?

“... Утызынчы елның июнендә таркатылган бу гаиләдән Юртайга кайтып йөрүче булмады. Бәйрәмханның әти-әнисе, хатыны Хурия һәм Бәйрәмхан үзе инде вафат, гүрләре Юртай карьясе каберстанында түгел, төрле төбәктә. Корбәтнең сеңелләре, хәтта өлкәне дә - Юртайдан киткәндә алты яшь булганы да – авылны хәтерләмиләр. Ә Корбәт авылны онытмый, аның анда бик кайтасы килә...

Кайтыр да иде... Ләкин әтисе белән аны алып киткән чакта йөз дә сигез ихатадан торган Юртай авылы беткән инде...”

Авылдашларның фаҗигале, михнәтле, газаплы язмышларының төп сәбәпләре нәрсәдә? Кайберләрен әсәрдә күреп үттек. Бәлки җаваплар бер генә төрле була да алмый торгандыр. Әмма тормышыбыздагы фаҗигаләрнең кимүгә йөз тотмыйча, гел арта гына торуы төгәлрәк җавапларны эзләргә һәм табарга куша.

Шундый җавапларның берсе “Чөй” (1991) исемле повестьта бирелә. Монда җитәкченең кансызлыгы, дорфалыгы, кеше язмышларына битарафлыгы һәм үзенең мин-минлеге авыл халкының берничә буынына зыян салып, агулап торганлыгы бәян ителә. Әшәкелекнең үзәге Моназыйр Шөгаетов дигән бәндәдә. Ул гомер буе авылның башында торып, башкаларны үз ихтыяры буенча гына яшәтергә күнеккән, гел шулай гына дәвам итәчәгенә инанган. Ул - рәхимсез рәсми идеология таләпләрен ләззәтләнеп тормышка ашыручылардан. Мөстәкыйль, хөр фикерлеләрне мәсхәрәләү, сыту, бетерү Моназыйрга чиксез рәхәтлек бирә. Әмма, ниһаять, Моназыйрларның кем икәнлекләрен, пычраклыкларын, вәхшилекләрен йөзләренә бәреп әйтерлек көн килә һәм шуны әйтердәй кешеләр үсеп җитә.

Повесть сюжетының үзәгендә нәкъ әнә шул гаделлекне күзгә карап әйтү көннәре тора. Фермага эшкә урнашкан яшүсмер кыз Рәисә, аның Әфганстаннан исән-имин әйләнеп кайта алган абыйсы Галияр, Моназыйр тырышлыгы аркасында төрмәдә утырып кайткан Сәрви карчык, балта остасы буларак, кешеләргә игелекләр кылып йөрүче сәрхүш Вафим, хәтта гомер иткән хатыны Гөлниса күп еллар буена эчләрендә яшереп саклаган ачу-нәфрәтләрен бер-ике көн дәвамында Моназыйр өстенә түгәләр. Башкаларны гел җәберләп, кешеләрне үзе өйрәтеп яшәргә күнеккән Моназыйр бер мәлгә бераз аптырабрак та кала.

Әсәр фаҗигале тәмамлана. Яраткан кешесенең – иренең авыл халкы каршындагы гөнаһларын күрә торып, дәшми генә, канәгатьсезлеген сиздермичә яшәгән Гөлнисаның акылына зәгыйфьлек килә, ахырдан ул, мунчаларына кереп асылынып үлә.

Хикәядә тирән мәгънәле деталь бар. Ул – Моназыйрның мунча түшәменә кирәксез урынга каккан тырма теше – тимер чөй. Баштарак аның бик тә кирәксезлеге һәм тиешле урында булмавын балта остасы Вафим әйтә. Соңрак хикмәтнең нәрсәдә икәнлеге ачыграк аңлашыла башлый – гомер буе кирәксезгә яшәгән, кешеләрне фәкать ул теләгәнчә генә йөртергә гадәтләнгән

Моназыйрның үзе авыл халкына гел комачаулык кына китереп торучы бер “чөй” икәнлеге мәгълүм була.

“Кирәксез төшкә чөй сукмыйлар... Елгасыз төшкә күпер салмыйлар...” Гөлниса әнә шул кирәкмәгән урынга суккан чөйгә бау бәйләп асылына. Метафораның тагын да киңрәк мәгънәсе җәмгыять тарихына карый. Авыл кешесе элек-электән үзенчә матур итеп яши белгән. Ә “чөй сугучылар” гасыр дәвамында аның нормаль, табигый, матур тормышына комачаулык иттеләр. Ә тоталитар режим үзе халык тормышына кагып куйган кирәксез чөй булмадымыни?

Утызынчы еллардагы репрессияләр темасы М.Хуҗин әсәрләрендә дә күренеп китә. Дәһшәтле, шомлы җилләр булачак әдипнең әти-әниләрен дә читләтеп үк узмаган. 1937 нче елны гаилә шул җилләрдән ышыкланып, туган авылын калдырып, Төньяк Уралга – Югары Губаха дигән җиргә килеп чыга, берничә айны шунда уздырып, исән-имин кала. Әмма бик күпләр монда да котылып кала алмыйлар.

“Куларада кәлтә уйный” (1989) хикәясендә шул шомлы вакыйгалар сабый бала күңеле аркылы тасвирлана. Хикәяләү мин исеменнән алып барыла. Яңа урын аңа шыксыз булып тоела, ул туган авылын сагынып интегә. Бер көнне шушында танышкан тагын ике малай – Искәндәр, Сәйферан белән бергәләп, нәни сеңелләрен дә арбага утыртып, шәһәрчек читенә - Куларага чыгып китәләр. Кулара дип бу якларда тауның уелып кергән үзәненә әйтәләр икән. Балаларның берсе гел үз авылын искә төшерсә, икенчесе шушы шәһәрнең зураеп, үсеп китүен, киләчәген уйлап хозурлана. Кинәт өчесе дә яннарына килеп чыккан иясез этләр өереннән куркып, бер мәлгә сүзсез – тавышсыз калалар. Тик эт өере дә бу балаларга тимичә үтеп китә. Ә аннан соң болар янына кечкенә кәлтә килеп чыга. Балалар шушы җан иясенең матурлыгын, кызыксынучанлыгына сокланып, тагын дөньяларын оныталар.

Ә кич аларны тагын кырыс чынбарлыкка кайтара. Эзәрлекләүчеләр, җәлладлар бу гаиләләр турында онытмаганнар икән. Сәйферанның әнисен кечкенә кызы белән биек әрҗәле машинага утыртып алып китәләр.

- Әнине алып китмәгез! – дип кычкырган Сәйферанның, кулларын каерып, эченә һәм башына тибәләр... Малай шуннан аңына килә алмый... Икенче көнне теге машина Искәндәрләр капкасы янына килеп туктый...

Хикәя болай тәмамлана: "Без дә Югары Губахадан китеп бардык... Илле тугызда бу якларга килеп чыккач, Югары Губахага башымны идем. Әтиләр... Әниләр... Тын урамыбызның изге җанлы кешеләре... Искәндәр – Александар... Сәйферан... Уенчак кәлтәле Кулараны эзләп табарга йөрәгем җитмәде".

Зур фаҗигале хәлләрне дә тирәнлеге, мәгънәсе белән кечкенә детальләр аша сөйләп бирә белә әдип. Кәлтә образы – зыянсыз, яклаучысыз җан иясе образы бөтен әсәрне тотып тора, шундый ук гөнаһсыз сабыйлар образларына ямь һәм мәгънә өсти.

"Мәгарә" хикәясен "Кулара..."ның дәвамы дип санарга була. М.Хуҗинның бик күп хикәяләре кеше гомеренең башындагы, сабый яисә яшь чагындагы булып үткән хәлләрнең, инде картайгач, гомер уртасында яисә ахырында кайтаваз булып яңгыравына, искә төшүенә корылган. Бу – гадәти яшьлек хатирәләрен искә төшерү генә дә түгел, ә егерменче-утызынчы елгылар буынының, илебез белән бергә кичергән авыр хәлләренең, фаҗигаләренең тибеше шактый еракка – безнең көннәргә кадәр барып җитүен искәртү дә. Дөрестән дә, моннан 60-80 еллар элек исә башланган ачы тарих җилләренең шыксыз салкынлыгы гасырыбыз тәмамланган чорда да күңелләрне өшетә, бүген авыр хәлдә илебез язмышының аянычлы сәбәпләре шул ерак елларга ук барып тоташа түгелме?

Әдипнең яшьтән күргән Губахасы да шул шыксыз, гаделсезлек, бетү, хәерчелеккә төшүнең билгесе, символы булып хәтерендә тирән уелып калган: "Урамнар чирәмсез... Шәһәрчекнең без утыз җидедә яшәгән урамында буш урыннар ишле, үзәктәге ике катлы йортларның күбесе ишексез-тәрәзәсез,

ишелгәннәре хәтсез... Утыз җидедә без качып яткан куларaны һәм шул тирәнең урманын-елгаларын кабат күрергә йөрәгем җитми. Ә ... иске шәһәрчектә - балачагым сукмакларында кабат-кабат йөрим. Туксан бернең апрель уртасы узгач бу.

Элек биек агачлар каплаган таулар шәп-шәрә. Шәһәрчекнең һәр ягы шулай. Югыйсә тауларга йортлар салмаганнар бит – урманнарны тамырыннан кыруның ни һаҗәте булды икән?..

Күмер беткәч, мәгъдәннәр ябыла – шахталар язмыш кочагында онытылып кала икән... Иске шәһәрчектә йорт тергезүче күрмәдем. Ятим йортлар... Авышкан коймалар... Җимерек сарайлар...”

Шушы ике хикәя белән танышканда ничектер Рәсәйнең XX гасыр дәвамында кая барганлыгының, тарихының бер кечкенә сурәтен, моделен күргәндәй буласың.

М.Хуҗин хикәяләренең үзәгеннән бик еш кешене аңламау, аны җәберләү, кимсетү, гадел булмау күренешләренә мөнәсәбәт, боларны кабул итмәү сызыгы үтә. Әти-әниләрсез, чит-ят җирләрдә, туган илләрен сагынып үскән буыны – Корбәтләр (“Кулаклар колхозы”), Искәндәрләр, үлеп калган Сәйфераннар (“Куларада кәлтә уйный”), гомер буе кыерсытылып, хәзер кешеләр янында яшәүдән мәгарәдә көн итүне артыграк күрүче булдыклы Миркадәмнәр (“Мәгарә”) – барысы да авторның йөрәк сызлануы белән иҗат ителгән образлар. Ирексездән заманында күңелләребезне тетрәндергән персонажлар – француз классигы Виктор Гюго романнарындагы хокуксызлар, җәмгыятьтән читкә тибәрелгәннәр – Квазимодалар, Сан-Вальжаннар, Гаврошлар, Козетталар искә төшә.

“Ак төенчек” исемле хикәясендә язучы татар халкының менталитетын чагылдырган әхлаклылык, иман, миһербанлык, тыйнаклык кебек сыйфатларның юкка чыга баруына борчыла.

“Авылның борынгы урамы Шушмага карый. Ул бер яклы, монда йортлар гадәти, зур-биек түгел, яңа йорт җиткерүчеләр дә монда олыдан купмый, хөсетләнеп, башка урамнар белән узышуга кушылмый. әмма

шунысы бар - башка урамнарда борынгы урам йортларының тәрәзә йөзлекләренә охшашларын күрә алмыйсың. Бизәкле йөзлекләрне Гайфарның этисе Хисаметдин ясый, елына бер йортка гына, Гайфар булышса да, артыгына көче җитми, җитмешенә бара...Башка урам осталары бизәк сызуда-кыруда Хисаметдиннән калышалар. Өйрәнмәделәр бит...” дип башланып китә хикәя. Язучының күп хикәяләре кебек бу әсәре дә авыл, аңа мәхәббәт белән сугарылган. Шулай ук автор каләменнән төшкән юлларда тирән сагыш чагыла. Элеккеге авылны, аның самими тормышын, оста куллы һөнәрчеләрен юксыну сагышы ул. М.Хуҗин бу хиснең көчлелеген элеккеге авыл күренешен җентекләүче детальләр аша сурәтләве белән күрсәтә. М.Хуҗин иҗатына хас булган салмаклык хикәянең камиллегенә, төп хасиятләреннән берсе булган кыскалыгына хилафлык китерми, ә, киресенчә, тәэсир итү көчен арттыра.

Хикәя авыл урамын сурәтләү белән башланып китә. Күз алдына бер-бер артлы тезелеп киткән йортлар, тар сукмаклар, яшел чирәмле капка төпләре килеп баса. Бизәкле тәрәзәләр, ара-тирә ярдәмчел, шат күңелле, гади авыл кешеләре күренеп китә. Боларның барысында да авторның элеккеге авылны сагынуы, аны матур буяуларга төреп сурәтләве чагыла. Язучы трактор-машина тәгәрмәченнән ермачланган урамнарны, гадилеген, эчкерсезлеген җуя барып, ямьсез гадәтләрне үз иткән авыл агайларын күрергә теләми. Авторга һәр урам, һәр йорт якын.

Хикәядә вак детальләр зур функция дә үтәргә мөмкин. Мәсәлән, бу очракта М.Хуҗин йортларның тигез түгеллеген башта ук искәртеп куя: “Арттагы урам ике яклы, киң, йортлар да биек, ике катлылары күп”. Аларның хуҗалары турында автор бер сүз дә әйтми. Бу очракта әлеге аңлатма кирәкми дә, чөнки язучы предмет детальләреннән бик оста файдалана. М.Хуҗин хикәяләрендә әйберләр хуҗалары турында үзләре сөйли, социаль хәлен күрсәтә. Шушма буенда урнашкан урамнар бер генә яклы, йортлары да кечкенә. Бу ике урамны тоташтыручы күпер дә җимерелү алдында. Шушы күпердәге фаҗигага автор укучысын әкрен генә алдан ук әзерли.

Бер-берсен яшьли сөюче Гайфар белән Сәрвиназны тоташтыручы күпер ул. Автор яшьләрнең мөнәсәбәтен сокланып, яратып сурәтли. Гомумән, М.Хуҗинның геройлары бер-берсен сөяләр икән, бу саф, илаһи, икеләнүләрсез мәхәббәт. Гайфар белән Сәрвиназга да бөтен авыл халкы соклана. Сәрвиназ иске күпер аша көн дә суга бара. М.Хуҗинга исә, кое суы эчмичә, элеккеге гадәт буенча, авыл халкының шушы күпердән чишмәгә йөрүе тагын да якын. Егет белән кыз да шунда очрашалар. Гайфар, күпергә карап, аның туза баруын искәртә. Шул урында М.Хуҗин хикәясен өзә дә безнең көннәргә кайта. Сәрвиназның сагышлануын сурәтли. Укучы фаҗига булганын белә, ләкин нинди икәнен автор һаман әйтми. Сәрвиназның уйланулары аша без тагын үткәнгә кайтабыз. Хикәядә вакыт хронотобы үзенчәлекле эзлеклелектә бирелә: үткән белән бүгенге көнне автор шундый оста итеп алмаштыра ки, хәтта укучы үзе дә күчкәнен сизми кала. Гайфар инде армия хезмәтен үтәп кайткан. Авылда аны сөйгән яры көтә. Ике өйдә тыз-быз чабышалар, кунак ашы пешә. Кунакчыл, аш-суга булган, сүзгә оста Фәрданә белән Хәйрия берсе булачак киленен, икенчесе кияүен сыйлый. Автор мич каршында коймак пешерүче ягымлы авыл апайларын да сагына.

М.Хуҗин яшьләрне һәм укучысын кабат күпер янына алып килә. Егет тагын күпернең тузганлыгына игътибар итә. (Инде икенче тапкыр автор моны Гайфар авызыннан әйттерә.)

Һәм, ниһаять, без нинди фаҗига булганын беләбез – Гайфарларның өе яна. Укучы автор тузган күпер турында сөйләде-сөйләде дә алдады дип уйлап куя. Тик ул ашыгыч нәтиҗә ясый. Шул рәвешле М.Хуҗин укучысын алдагы зур фаҗигага әзерләп куя: Гайфар трактор белән узганда күпер ишелә.

Әдип, Сәрвиназ белән Гайфарның тугры эте Игәрне ияртеп, укучысын янә күпер янына алып килә. Язгы ташу ургылып ага. Шундый вакыйгадан соң да, күпер төзәтелмәгән, ә калган өлешләреннән басма әмәлләп куйганнар. Инде өченче фаҗига – Сәрвиназ белән эт басма ишелеп һәлак булалар.

Хикәя болай тәмамлана: “Елга аша яңа күпер салырга карар чыгарганнар. Карарсыз гына, бераз элегрәк салып булмады микәнни соң ул күперне?! Булмагандыр шул…

Шушма тын гына ага. Әмма агымында шом куера. Яңа хәвеф килмәгәе…” Бу юлларның Шушма һ.б.турында гына түгел, ә кешелек мөнәсәбәтләре, аралашу, аңлашу күперләренә хәвефләр килмәсен иде дигән автор фикере бик ачык сизелә. М.Хуҗин, поэтик детальләрне философик яссылыкка күчереп, кечкенә күләмле әсәрне масштаблы итә белә. Яшьләрнең фаҗигале мәхәббәте – бу хикәянең өске катламы гына. Ә автор әйтергә теләгән фикер, аның уе тирәнгә яшерелгән. Шуңа күрә М.Хуҗинның хикәяләрен зур дикъкать белән, юл араларына игътибар итеп укырга кирәк. Хикәянең төп эчтәлеге соңгы юлда бирелә, укучы авторның төп максаты яшьләрнең фаҗигале мәхәббәтен сурәтләү генә түгел, ә безнең җәмгыятьтә гади кешегә карашның әлегә бик түбән булуын күрсәтү икәнлеген аңлый.

М.Хуҗинның күп хикәяләренең үзәгендә сугыш чорындагы авыл, тыл тормышы, бу чорда хатын-кызларның, яшүсмер егет-кызларның авыр хезмәте тасвирлана. Үзе дә сугыш чоры баласы буларак, язучы бу вакыйгаларны оста, реалистик планда, сәнгати югарылыкта бәян итә. Биредә дә автор заман авырлыклары, илдә барган вакыйгалар турында гына сөйләп калмый, ә аерым кеше күңелен ачарга, аның тирән төпкелендә яткан хис-кичерешләрне укучысы алдында тасвирларга омтыла. Хикәя җирлегендә яшүсмер малайның этиләре-абыйларына йөкләнгән авыр хезмәтне ничек башкаруы, Хәервафа, Сафифә апаларның тылдагы батырлыклары гына түгел, ә бу дәһшәтле елларның алар күңеленә тәэсире, рухи халәте тасвирлана.

Хикәя, гадәттә, бер вакыйга тирәсенә туплана. Язучы киеренке бер вакыйганы алып, шуның тирәсендә геройның үсеш-үзгәрешен күрсәтә. Автор я мин исеменнән, яки сурәтләнгән вакыйгаларга читтән карап өченче заттан сөйли. М.Хуҗин да күп хикәяләрендә бу классик алымга тугры кала. Ләкин әдип чит ил әдәбиятын, рус һәм татар әдәби мирасын, хикәя жанрының үсешен, тарихын, аның бөтен хасиятләрен тирәнтен өйрәнгән язучы буларак

үзенчәлекле алымнар белән эш итәргә дә омтыла. Мисалга “Ипи.Колын.Без.” әсәрен генә алыйк. Бу хикәя М.Хуҗинның үзе исән вакытта матбугатта дөнья күргән соңгы әсәрләренең берсе. 2002-2006 елларда иҗат ителгән бу әсәргә язучының дистә еллар буена җыйган тәҗрибәсе кергән, аны гадәтилектән калкыбрак торган әсәр дип карарга да була. Хикәя автор һәм геройлары тарафыннан бәян ителә. Шул рәвешле вакыйгаларга төрле караш сурәтләнә. Аларның бер сызыктан үсүе-үзгәрүе генә түгел, ә тукталып тасвирлануы да күрсәтелә. “Ипи. Колын. Без.” хикәясендә хәзерге көн һәм геройның истәлекләре аша 1920-30 нчы елгы вакыйгалар сурәтләнә. Әсәр шул чор, заман хорафатларының аерым кеше язмышларына фаҗигале тәэсире хакында.

Әсәрнең үзенчәлеге, уникальлеге иң беренче чиратта сюжет төзелешендә чагылыш таба. Хикәяне берничә өлешкә бүләргә мөмкин. Беренчесе Гәрәйхан исемле малай тарафыннан сөйләнелә. Анда ипи салу вакыйгасы тасвирлана. М.Хуҗин Гәрәйханның сеңелесе Сәгадәт белән әниләренең ипи пешергәнен карап утыруларын малай исеменнән бик җентекләп, әлеге эшнең башкарылу рәвешен тәфсилләп сурәтли. Өйдә ипи салу, ипи пешерү онытыла барган заманда бу эшнең бөтен нәзакәтлеген күрсәтү актуаль, әлбәттә. Ләкин язучының бу күренешне иң алга чыгарып, иркенләп тасвирлавы бу эшнең әһәмиятлелеге, мөһимлеге, изгелеге белән генә бәйле түгел. Хикәянең исеменең үк бер өлешен тәшкил иткән “ипи” алга таба да әсәрдә чагылыш табачак. М.Хуҗин ипине туган тел белән янәшә куя. “Адәм баласы икмәк тәмен һәм үз теле тәмен беркайчан да онытмаска тиеш. Боларның икесен дә башлап әни пешереп бирә”, - дип әйттерә автор героеннан. Шул рәвешле кечкенә хикәя мәйданында глобаль проблема күтәреп чыга. Гәрәйхан язмышы үрнәгендә теләк булганда чит җирдә дә телне саклап калу, онытмау мөмкин икәнлеген күрсәтә.

М.Хуҗин ипи пешергәндә кулланыла торган һәр әсбапны исеме белән атап, аның нәрсәгә яраклыгын тасвирлап яза. Бу очракта ул бик отышлы алым куллана. Язучы коры тасвирчылыкны читләтеп үтә. Барысы да укучыга

ана аңлатуы аша барып җитә. Ләкин ипи пешерү процессы белән беррәттән хикәядә сурәтләнгән вакыт хронотобы да күз алдыннан югалтылмый. Язучы бик оста табылган детальләр аша әсәрдә ачлык чоры гәүдәләнә. Гаиләгә ашарга җитәрлек булмавын читләтеп сиздереп куя. (келәт ябык тора, эре иләк, кечкенә янчык).

Ипи пешерү вакыйгасы өзелә дә, әсәрнең икенче өлешендә язучы хикәяләүне үз кулына ала. Монда вакыйга язучы өенә күршесе килеп керү белән башланып китә. Бу өлештә хикәя эчендә хикәя дип алырга була. Беренче бүлектән аермалы буларак вакыйга бүгенге көндә бара. Хикәядә вакыт хронотобы үзгәрештә бирелә. Автор үткәннән әле бүгенгегә, әле киресенчә, бүгенгедән үткәнгә күчә. Вакытка бәйле рәвештә хикәяләүче дә үзгәрә. Үткәннәр Гәрәйхан исеменнән сөйләнелсә, хәзерге вакытта барган вакыйгаларны автор бәян итә.

Хикәянең сюжеты бер линия буйлап кына бармый. Әсәрдә капма-каршы якка үзгәрешләр, кискен борылышлар хәтсез урын ала. Күп очракта көткәннең киресе килеп чыга. Ипи пешкәч, балаларның тамагы туя дип көткәндә генә бу сөенечле вакыйга кайгы алып килә. Әниләрен кулга алалар, балалар ятим кала. Хикәяләүче ишек шакыганга “бала кешедер, кыңгырауга басарга буе җитмидер” дип ишеккә барса, анда “озын ук гәүдәле, ыспай киенгән, дулкынлы кап-кара чәчләрен ипле тараган, өлкән үк яшьтәге абзый-бабай басып тора иде”. Борынгы греклар мондый борылышларны перипетия дигән сүз белән билгеләп йөрткәннәр. Кискен борылышлар белән эш итү язучыдан зур осталык таләп итә, укучыны ышандырырлык итеп сәнгатьчә ныклы нигезләүне, дәлилләүне сорый. М.Хуҗинда исә нәкъ мондый осталык бар. Ул кискен борылышларны кыскалык белән үзара яраштырырга да сәләтле. Бу үзенчәлек “Ипи. Колын.” хикәясендә генә түгел, ә башка әсәрләрендә дә чагылыш таба. “Каңгый илендә” хикәясендә, мәсәлән, шулай ук сюжетның кискен борылышын, төп герой Хәяли язмышындагы кискен үзгәрешләрне күзәтергә мөмкин. Шуңа күрә перипетия алымын М.Хуҗин стиленә хас дип әйтә алабыз.

Хикәянең ахыры да бик тәэсирле бирелгән, шулай ук кискен борылышка корылган. Гомумән, М.Хуҗин хикәяләрен тәэсирле тәмамлый белә. Ул укучысына уйланырга урын калдыра.

Әсәрдән күренгәнчә, озак еллар узгач, Гәрәйхан авылына кайтып, туган нигезендә йорт тергезүгә ирешә. Сеңлесен эзләп таба. Инде бар да көйләнде, бәхетле бергә-бергә тормыш итү сурәтләнер дип көткәндә, әсәргә тагын кискен борылыш килеп керә. Сәгадәт кире үзе яшәгән шәһәргә китәргә карар кыла. Аның бу теләге табигый да. Чөнки Омск шәһәрендә ул гомеренең күп өлешен яшәгән, шунда хезмәт иткән, иренең кабере дә шунда.

Хикәянең финалы уйландыра. Укучыда сорау туарга мөмкин: барысы да җайлангач, Сәгадәт ник китәргә уйлаган соң, чит җирдә аның беркеме дә юк бит? Бу сорауларга хикәянең соңгы җөмләсе – Гәрәйхан сүзләре ачык җавап: “Шулай, яшьтәш, безнең кызлар барган җирләреннән кайтучан түгел”. Бу сүзләр Сәгадәт характерына хакында тулырак мәгълумат бирә, аны тугры хатын буларак тасвирлый. Ә “безнең кызлар” дип әйтү Сәгадәт образын гомумиләштерә, авторның Сәгадәт образы аша татар хатын-кызларының гомуми образын сурәтләргә омтылганын белдерә.

М.Хуҗин хикәяләренең исемнәренә дә зур функция йөкли. Аның “Кеше күңеле – үзе бер кояш”, “Айның уты сүнгән”, “Мәхәббәт – һәлакәт?!”, “Ул урамнан дүрт уза...” һәм башка хикәяләренең исемнәре үк уйландыра, укучыны фикер йөртергә этәрә. “Ипи. Колын. Без.” хикәясе исеме белән дә татар әдәбиятындагы башка әсәрләрдән аерылып тора. Аның исеме әсәрдәге вакыйгалар агышының төп моментларын чагылдыра. Гәрәйханның әнисе ипи пешерә. Малай үзенә тиешле икмәк сыныгын колынына ашата. Бу авыр елда атка ашатырдай икмәк аларга каян килгән дип өйләрен тентиләр һәм әниләрен кулга алалар. Ә “без” – ул икесе ике җирдә, чит кешеләр арасында үскән, бер-берсенә ят кешегә әверелгән туганнар – Гәрәйхан һәм Сәгадәт, шул ук вакытта автор-хикәяләүче образы аша бөтен җәмгыять.

М.Хуҗинның Габдулла Тукайга багышланган матур гына ике хикәясе бар: «Кеше күңеле – үзе бер кояш» һәм «Иңә дә иңә карлар» дип атала алар.

Бу әсәрләрдә сөекле шагыйребезнең тормышында чыннан да булган яки булырга мөмкин вакыйгалар, фараз итеп кенә күз алдында җанландырышсалар да, тормыш дөреслеге, Тукайга булган чиксез мәхәббәт, сүзләрдән сурәт тудыру кебек язучылык могҗизасына изге бер эш итеп хөрмәтләп карау бөркелеп тора.

Сәламәтлеге начарлангач, авылга кайтып, хәл җыеп, тернәкләнергә тырышучы шагыйрьгә җиңгәсе Рабига, аның күңелен күтәрергә теләп, сүз уңаеннан гына болай дип әйтеп куя:

– Юкка пошынасың икән лә, Габдулла... Шагыйрьне оныталар димә инде?! Гомер-гомергә булмаганны! Китапка язмаганны! Шагыйрьне, сине онытсалар да, нигә әле бу начарлык миннән башланырга тиеш ди?! Барлык юньсезлек шагыйрьне санга сукмаудан башлана, бик беләсең килсә!.. («Иңә дә иңә карлар»).

Гади генә авыл хатыны әйткән бу сүзләр кинәт сискәндереп җибәрә. Гадәти сүз сөрешеннән килеп чыккан мондый тирән мәгънәгә М.Хуҗин әсәрләрендә еш юлыгасың... Тукайлар, әлбәттә, онытылмый – алар бөеклекне иҗатлары һәм тормышлары белән яуладылар. Әмма бүгенге ыгы-зыгылы тормышта шагыйрьләрне, язучыларны, гомумән, әдәбият кебек изге һәм игелекле эшне санга сукмау күренешләре дә тулып ята. Һәркемгә мәгълүм: бүгенге сәясәт «кеше рухы инженерларының иҗат казанышларын күрергә дә, бәяләргә дә ашыкмый. М.Хуҗин хикәясендәге ишарәнең дә 1912 ел вакыйгаларыннан хәзерге 90 нчы елларга күчкәнлеге бик җиңел аңлашыла.

Язучы М.Хуҗинның китапларын актарганда әлеге проблеманың соңгы вакытта аеруча кискенләшүен тоясың. Артык еракка карамыйча, үзебезнең каләм әһелләренең, тәнкыйтьчеләрнең, әдәбият белгечләренең әйләнә-тирәбездәге мул рухи хәзинәгә мөнәсәбәтләренә генә игътибар итегез. Тәнкыйть, әдәби җәмәгатьчелек күбрәк мәшһүр исемнәр тирәсендә кайнаша. Анысы да ярар иде, әгәр... әгәр әдәбиятның бүгенге «эш атлары» читтә калмаса...

М.Хуҗин хикәяләрен укыганда назлы җылылыкны – яхшы күңелле кешеләр күңелендәге нурларның гүя үз күңеленә күчүен тоясың. Хикәяләренең геройлары да – шул матурлыкны үзләрендә йөртүчеләр. Кемнәр икән соң алар? Берничәсенә генә күз салып үтик.

Шимай белән Фәрхиянең тормышлары («Мәк чәчәге») беренче карашка бүтәннәрнекеннән берни белән дә аерылып тормый кебек. Кулларыннан эш тә килә. Менә дигән җиләк-җимеш бакчасы да ясаганнар. Анысы кемдә юк инде аның хәзер, тик менә шунысына игътибар итегез: бу бакчага кереп, теләсә кем сыйлана ала. Агачны гына сындырма һәм яшелчәне генә таптама. Балаларга карата бу юмартлык әллә үз балалары юклыктан килә инде... Малай чагында Шимай кеше бакчасына кереп чәчәк өзмәкче булган. Хуҗа аткан балта малайның бот итен уйган. «Мин балта тигәч, егылдым, хуҗа куып җитте, эчемә чабатасы белән дыңгылдатып типте дә, әрекмән өзеп, балтасындагы канны сөртә-сөртә китеп барды... әрекмән яфрагы кычыткан өстенә шәлперәеп кунды. Мәкнең сулган чәчәге кебек тоелды ул миңа... Бәлки, малайларны сыйлавыбыз шуның өчендер».

Бу ямьсез вакыйга биредә кара белән акны капма-каршы кую, ягъни контраст сурәт булуы белән кызыклы. Әнә шушы караңгылык белән яктылыкны аерып торучы сызык геройларның тормышларын телгәләп, хикәядәге бүгенге көннәренә кадәр килеп җитә. Тормышлары көйсезләнгәнрәк икән шул: Шимай әкренләп эчкечелеккә бирелеп бара, Фәрхиянең дә күңеле бигүк тыныч түгел – иренә ышанычы кимеп барган кебек тоела аңа. Менә шундый тәшвишләнеп йөргән көннәрнең берсендә Шимай уйларында борылыш була, аның көнкүреше дә кинәт үзгәреп, яктырып китә – борчыла-уйлана торгач, чәчәк кебек гомерне горур да, матур да үткәрергә кирәклеген бөтен күңеле белән тоя.

Мондый үзгәреш сугыштан гарипләнеп кайткан Мифтах күңелендә дә була («Төнге сулар челтери»). Бу юлы да якын кешеләр арасындагы фараз гына ителгән аңлашылмаучылык, шик-шөбһәләр бер мизгелдә юкка чыгалар. Башкача була да алмый: изге күңелле кешеләр, әлбәттә, матур язмышка

лаеклылар – монысы әдипнең теләге, омтылышы, әгәр шулай дип әйтергә яраса – иҗат кредосы.

Мөршидә белән Мифтах Ватан сугышында ике газиз улларын югалтканнар. Хәзер менә Мифтах та, «ярты гына кеше бит мин», дип гарьләнә. Әмма әсәр ахырында Мөршидәсенең яшь чагындагы «Матур син, Мифтах. Йөзең генә димим, җаның да матур» дигән сүзләренең яңадан яңгыравы соңгы юшкыннарны юып төшерә.

М.Хуҗин хикәяләрендә әдәби деталь бик зур әһәмияткә ия. Гомумән, тирән мәгънәле, кинаяле, әсәргә ямь биреп, аны мәгънәле итеп яктыртып торучы детальдән башка хикәя туа да, яши дә алмый. Кызганычка, кайбер язучылар бүгенге заманда төрле юк-бар хәлләрне аннан-моннан бик примитив рәвештә сөйләп бирүне дә безгә хикәя дип тәкъдим итәләр. Ә М.Хуҗин әдәби деталь алымнарыннан бик уңышлы файдалана. Берәр мисал китереп үтик.

Кырның иңкүрәк бер җиреннән чишмә тибеп утыра. Кыш буена яуган карлар да аны томалый алмый, тирәләп бүрәнә калдыралар («Тәпәнле чишмә»). Күп еллар шулай булган. Әмма бүген инде ул арыган, тибүе сизелми. Шушы чишмәгә гомере-язмышы бәйләнгән Ләзизә дә олыгайган. Һәм автор әлеге чишмәгә мөнәсәбәттә кеше язмышлары хакында сөйли башлый. Сиксәнгә җитеп килүче Шәмсун карт көннәрдән бер көнне Ләзизә карчыкка килеп сүз куша: калган гомеребезне түгәрәкләп, бергә яшәсәк иде, зиратка барып, карчыгым Латифаның да ризалыгын алырбыз, ди. Тик Ләзизә карчык «Минем сугыштан кайтмаган Зөбәеремнен ризалыгын ничек алырбыз соң? Юк бит аның гүре, исән бит ул», дигәч, Шәмсунга «Син хаклы, Ләзизә» дип чыгып китәргә генә кала.

Заманында Зөбәер, төннәрен сиздермичә генә югалгалап, әлеге чишмәне табып, ачып, казып, рәтләп йөргән икән. «Синең өчен эзләп таптым бу чишмәне», дип Ләзизәне сөендергән, әле ул гармун да ясаган икән. Хикәя болай тәмамлана: Шәмсун карт хәзер чишмәне үзе чистартып йөри һәм карчыкның ихтирамын да казана – Ләзизә рәхмәт әйтеп кенә калмый, «Зөбәеремө тапшырырсың, мин үлгәч» дип, әманәт итеп теге гармунны да аңа

бирә. Биредә чишмә һәм гармун – лирик деталь-бизәкләр генә, әмма уйлап карагыз – шулардан башка бу бик матур хикәя туа һәм яши алыр идеме? «Тәпәнле чишмәнең уртасыннан тигез генә кайтарылып-ишелеп су ага. Аның суы кимеми... Йөрәктә дә мәхәббәт нәкъ әнә шулай кайныйдыр сыман».

Новелла кануннары буенча (сюжет борылышларының мәгънәлелеге, кинаяле, ишарәле фикер тыгызлыгы, көтелмәгән тәмамланыш) эшләнгән бу төзек әсәрне якын кешеңне онытмау, сагыну, көтү идеясе сугарып тора.

Хикәя – ул бик кечкенә жанр, гадәттә ул бер вакыйганы, бер мизгелне генә үз эченә ала, дип сөйлиләр. Әмирхан ага Еникинең «Җиз кыңгырау» яисә «Тауларга карап» кебек әсәрләрен генә искә төшерик. Язучы М.Хуҗин да шундый хикәя тарафдары. Бу хикәяләрдә гыйбрәтле тормыш юлын үткән карт-карчыкларның күп булуларына гаҗәпләнергә кирәкми торгандыр. Нәкъ менә шуларның бай язмышлары авторга әдәп-әхлак кагыйдәләренә тугрылык, һәр гамәлдә кеше булып кала белү сәләте хакында тулы һәм образлы итеп сөйләү мөмкинлеген бирә.

М.Хуҗин хикәяләрендә бигүк гадәти булмаган, сәеррәк холыклы, хәзергечәрәк итеп әйтсәк, экзотик карт-карчыклар да күренгәли. Бу кешеләр бүгенге халәтләре белән генә түгел, ә узган гомер юлларының үзенчәлекле булулары белән дә кызыклылар.

Менә гомере буена туган авылыннан чыкмавы хакында сөйләргә яратучы удмурт карты Петрухның тормыш фәлсәфәсе («Соң»):

«Миңа бит көн дә бәйрәм. Күзем ачылгач та күргән әйберләрне көн саен кабат күрәм мин, үзгәрешләрне белеп торам. Бер күргән урынны икенче тапкыр күрә алмау – бәхетсезлектер ул. Минем хәтта беркайчан күрше авылга да барганым юк».

Сәеррәк шул бу Петрух дәдәй – Василий Шукшин геройлары бер яктарак торсыннар! Әмма ул үзенең сәер карашларын бүтәннәргә көчләп такмый:

– Мин авылыбыз тирәсеннән ерак китә алмыйм. Ә балаларым ил гизә. Йөрсеннәр – теләкләре...

Әсәр ахырына калдырылган бер штрих сөйкемле, тыйнак картның характерын тулыландырып җибәрә һәм вакыйганы да чын хикәягә әверелдерә: Шулай да Петрухка авылдан китәргә туры килгән икән. «Сугыш кырына барып кайттым. Гитлерның миңа дигән «күчтәнәче булган икән, мина кыйпылчыкларын санаусыз тутырган иде, докторлар чүпләп бетерә алмый озак интектеләр».

«Зөбәер әби бирнәсе» исемле хикәядәге йөгерешче Нуришан картны да гадәти, нормаль кешеләр рәтенә кертеп булмый торгандыр. Тик аның кыланышларында да әйләнә-тирәдәгеләргә гел яхшылык кына ята. Каты авырып киткән балага ерак авылдан табиб чакырам, дип йөгереп чыгып китсә дә, ярты юлдан кире борылып кайтып оныкның үзен күтәреп йөгерә һәм баланы хирург алдына китереп сала ул. Заманында йөгерешче малай, соңрак Йөгерешче абый, Йөгерешче бабай – Сабан туйлары, ярышлар җитә башласа, урынында басып тора алмый, аны беләләр һәм шушы тынгысыз, ярдәмчел, яхшы күңелле кешене олысы-кечесе дә хөрмәт итә. Менә карт үлеп китә – алдагы Сабан туйлары инде аннан башка үтәчәк. Бу авылда элек-электән картлар йөгереше уздырыла икән. Бу юлы мәйданга карты урынына карчыгы килеп чыга, башка карт йөгерешчеләр аны узарга тырышмыйлар, акрынаеп, гадәттә ел да Нуришан ала торган бирнәне бу юлы карчыкка алырга мөмкинлек бирәләр. Олы кешегә булган хөрмәт яңадан аны табып, үзенә әйләнеп кайта.

Кайсы гына хикәяне алып карасак та, изге рухлы, кешеләргә яхшылык иңдерүче затларга һәм шуларның эш-гамәл, вакыйга-хәлләре аркылы югары әхлаклылык күренешләренә юлыгырбыз. М.Хуҗин хикәяләренең төп сыйфатларының берсе итеп бик үтемле, шул ук вакытта югары әдәби техникага нигезләнгән чаралар ярдәмендә чын әхлак кагыйдәләрен-нормаларын, күренешләрен укучыларга җиткерү дип атарга була. Бүгенге талымсызлык, зәвыксызлык, тупаслык һәм пычраклыкны әдәби продукция рәвешендә тәкъдим итү киң таралган заманда М.Хуҗин прозасының нәкъ энә шул ягы, шул хасияте, әлбәттә, дөрес һәм югары бәяләнергә тиеш. Әдип

тормышның төрле, хәтта ямьсезрәк якларын читләтебрәк үтә икән дигән фикергә урын калмасын. Ул тормышның төрле якларын шактый иңли, тик шулай да нужа, язмыш бабай тарафыннан кыйналган, имгәтелгән затлар турында сөйләгәндә дә үзенең төп принципларына тугры булып кала.

Авыр сугыш елларында («Мәхәббәт бит ул») яшь кыз тракторчы Мәйсәрә кырда сукачы егет телсез Ләбиб белән бергә эшли. Яратышып, бергә тормыш та корып җибәрәләр. Сөйләшә белмәсә дә, Ләбиб Мәйсәрәнең тормыш терәгенә әверелә, матур кыз үстерәләр, соңрак оныклары да дөньяга килә. Шушы язмышларны автор өч-дүрт битле хикәя эчендә сөйләп бирә алган. Моның өчен ул хикәяне өч өлешкә бүлгән. Өч күренеш. Өч мизгел. Әмма шул өч мизгел арасына гаиләнең гомер юлы сыйган. Беренче күренештә Ләбиб кырда кинәт сүнгән тракторына карап аптырап калган Мәйсәрәгә ярдәм итә – керосины гына беткән икән, икенчесендә, кызы Әнисә янындагы Ләбибнең балаларча кыланышлары, өченчесендә Ләбибнең яңа туган оныгын каршылау куанычы. Мәгълүм ки, героебызны әдип берничек тә сөйләттерә алмый, бу очракта фәкать шушы күренешләр ярдәмендә генә Ләбибнең кер кунмас изге җан икәнлеге бик матур әйтеп бирелә.

Акылга зәгыйфьрәк Вильдан турындагы («Оча кошлар») вакыйганы да автор кызыклы сюжет кысасына төреп, гыйбрәтле һәм тәрбияви итеп сөйләп бирә алган. Вильдан үзе тилемсәрәк булса да, моңлы кеше икән: аның өйдән-өйгә йөреп, гармун тартып, хуҗаларның күңелләрен ачып йөри торган гадәте-сәләте бар. Бер көнне Шәфыйка да аны үз өенә чакырып ала һәм фронтка киткән ире Тимершаның яраткан көе «Уел»ны уйнавын үтенә, соңыннан «Тимерша абыең посылка җибәргән, шушы күлмәк белән сәгатьне Вильдан энемә бүләк ит», дип әйткән, – ди.

«Вильдан сәгатьне учында кош баласы кебек итеп тотты. Аннары гармуны өстенә куйды да озын телнең акрынлап күчүен озаклап карап торды.

– Рәхмәт Тимерша абыйга, рәхмәт икегезгә дә. Тимерша абый яраткан

көйне тагын бер уйныйм әле.

– Уйна, Вильдан энем, уйна, әле дә син күңелне ачып йөрисең авыр көннәрдә... Бик изге синең һөнәрең».

Бичара, риясыз-зыянсыз Вильдан шулай йөри торгач, үлеп тә китә. Сугыштан исән-сау кайткан Тимерша аны үз куллары белән җирли, хәтта теге сәгатьне дә кабер өстенә куеп калдыра, «шатланып ятсын, үзе дә кешеләрне шатландыра белә иде, үзең шатлана белмәсәң, бүтәннәрне сөендерә алмыйсың шул», ди. М.Хуҗинның күп хикәяләрендә әнә шундый башкаларны сөендерерлек шатлык бар. Һәм менә әсәрнең финалы – ул мәшһүр О.Генри новеллаларыныкы дәрәҗәсендә: Тимерша фронттан теге посылканы «балалар ишле, ашау-эчү такы-токыдыр, сәгать белән күлмәкне сатып, азрак ризык юнәтер» дип Шәфыйкага җибәргән булган икән, ә ул иренең исән-сау булу куанычыннан күчтәнәчләрне Вильданга биргән... Кем турында булды соң бу хикәя? Әлбәттә Вильдан турында гына түгел. Хикәяче М.Хуҗин стиленең бер үзенчәлеге шунда – бер персонаж тирәсендә бөтенләй яңа образлар яктыра – бу хикәядә дә нәкъ шулай. Олы җанлы Шәфыйка белән Тимершаның мәхәббәтләре, аерылу сагышы, кавышу шатлыгы һәм сөйкемле Вильданның кайгылы истәлеге – боларның бөтенесе бергә хикәяне тудыра.

Хикәя – җыйнак, кечкенә, ләкин катлаулы һәм авыр жанр. Романчы яисә повестьчыдан аермалы буларак, хикәяче бик тар мәйданда эш итә. Биредә шагыйрьләрчә мәгънә һәм хисләр тыгызлыгына ирешергә кирәк. М.Хуҗинның лирик прозасы чыннан да шигърияткә бик якын тора. Шулай да бу шигърият реаль тормыш чынбарлыгы, аерым алганда, күпне күргән, белгән авыл кешесенең аек табигате-халәте белән дә аралаша: «Көзге көн иде. Көн тиз бозыла. Карлы-бозлы яңгыр ява, көзен юеше үзәккә үткәреп, төнне тырный. Җәяүләп күп барып булмый, ботинкага табак-табак олтырак сыман пычрак ябыша. Тәгәрмәч тимерләрен кыру файдасыз, бер әйләнүгә тагы поты белән пычрак төялә, күчәр башларына төшеп бөялә. Атлар көчәнеп, җил ягыннан башларын яшереп тарталар» («Курагай атлары»).

М.Хуҗин – авыл табигатен-хәлләрен вакытлыча ял итәргә кайткан кеше карашыннан бәяләүче яисә сурәтләүчеләрдән түгел. Авыл аның төп темасы булып, бөтен иҗаты буенча килә. Татар әдәбиятында сугыш чоры һәм сугыштан соңгы еллар татар авылын искиткеч дөрес һәм ышандырырлык итеп сурәтли белгән каләм осталары аз булмады. Рафаил Төхфәтуллин, Гариф Ахунов, Нурихан Фәттах, Әхсән Баян, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Вакыйф Нуруллин кебек әдипләр кырыс тормыш чынбарлыгын үз белгәннәре, үз кичерешләре аша төгәл һәм күпләрне дулкынландырырлык итеп китап битләренә күчерә алдылар. Нәкъ шушы сәхифәләр гасырыбызның икенче яртысындагы татар прозасының ныклы реалистик җирлектә калуын раслады. Әлеге исемлектә һичшиксез М.Хуҗин исеме дә урын алырга тиеш, башкаларга охшаган яисә аларны кабатлаган өчен түгел, ә киресенчә, 1940-70 нче еллар татар авылының яшәешен, сулышын бик яхшы белеп, тасвирлау осталыгы өстенә, шул чынбарлыкны һәм заман геройларының бай рухи дөньяларын үзенә генә хас бер сизгерлек, тыйнаклык һәм әдәплелек белән ачып бирә алган өчен.

Бу тезисны күпсанлы әдәби мисаллар ярдәмендә тулырак ачып та булыр иде. Шуларның берсенә – элек-электән, йөз еллар буена кристиәннең канаты булып саналган ат образына гына игътибар итик: «Курагай атлары», «Ак колын», «Өч каен ышыгы» кебек хикәяләрдә татар әдәбиятының шушы юнәлештәге иң яхшы традицияләре бик уңышлы дәвам иттерелә, биредә авыл кешеләренең таянычы булган атларга хөрмәт гимны гына яңгырап калмый, бу ихтирам аларны аңлаучы хуҗаларга – кешеләргә дә күчә. М.Хуҗин иҗатының бу ягы үзе махсус өйрәнүне-тикшерүне сорый.

М.Хуҗин бик күп газета-журналларда бүлек мөхәррире, мөхәррир, җаваплы сәркатип вазифаларын башкара. Төрле редакцияләрдә эшләгән вакытта да әдип хикәя жанрына тугры кала. М.Хуҗин әсәрләр иҗат итүдән тыш башка язучыларның хикәяләрен туплау, аларның иң яхшыларын сайлап матбугатка чыгару белән дә шөгыльләнә. Ул төзегән татар хикәяләре

антологиясе буенча әлеге жанрның татар әдәбиятында үткән юлын күзәтергә мөмкин.

М.Хуҗин эпик төрнең кыска күләмле жанры мәйданында яшәешнең төрле якларын, кеше күңеленең үзгәреш-кичерешләрен нечкә детальләр, сурәтләр ярдәмендә ачып сала иде. Бу максатны тормышка ашырганда язучы хикәя жанрының бөтен хасиятләреннән дә оста файдаланды. Аның әсәрләре татар хикәяләренең якты үрнәге булып тора.